**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ГЛАВА**
**города Азнакаево Азнакаевского муниципаль районы**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре БАШЛЫГЫ**

Ленин ур., 22 й., Азнакай ш., 423330
Тел. (885592) 7-24-83, факс (885592) 7-23-85
mailto:adm@aznakay.gov.tatarstan.ruE-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

Ленин урамы, 22 йорт, Азнакай шәһәре, 423330
Тел. (885592) 7-24-83, факс (885592) 7-23-85
mailto:aznakay@tatar.ruE-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

“30” сентябрь 2022 ел № 283

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлегендә гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә карар бирәм:

1. 2022 елның 11 октябрендә 17.00 сәгатькә, Стәрле Елга урамы, 9 йорт янындагы Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлеге торак пункты территориясе өлешендә гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлеге торак пункты территориясенең әлеге өлешендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын уздыру өчен территориянең бер өлеше чикләрен түбәндәге гражданнар яши торган территорияләр чикләрендә расларга:

- Стәрле Елга урамы 9 йорттан 26/2 йортка кдәр торак йортлар.

3. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясе өлешендә - Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре башкарма комитетын үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын оештыручы итеп билгеләргә.

4. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре башкарма комитетына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

- 2022 елның 03 октябреннән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре башкарма комитетында гражданнар җыенын хәл итүгә чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын түбәндәге адрес буенча оештырырга: Азнакай шәһәре, Ленин урамы, 14 йорт;

- сайлау хокукына ия булган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Стәрле Елга урамы буенча 9 йорттан 26/2 йорт буенча "Азнакай шәһәре" муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлешендә яшәүчеләр исемлеген төзергә;

- гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерләргә;

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Стәле Елга урамы буенча 9 йорттан 26/2 йорт буенча массакүләм мәгълүмат чаралары һәм башка ысуллар аша "Азнакай шәһәре" муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлешенә гражданнар җыены турында халыкка хәбәр итәргә.

5. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны түбәндәгечә расларга:

"Сез, 2023 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлешендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 1 төркем инвалидлардан, көндезге уку формасы студентларыннан кала һәр балигъ булган кешедән 2000 сум күләмендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкару буенча үзара салым кертүгә ризамы:

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлегенең Стәрле Елга урамы 9 йорттан 26/2 йортка кадәр җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тоту (юлларны асфальт-бетон белән каплау, төяү, ташу, асфальт-бетон салу, шартнамә буенча эшләр башкару).".

«РИЗА» "КАРШЫ"

6. Әлеге карарны кабул ителгән көннән алып 2 көн эчендә, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга: http://aznakayevo.tatar.ru.

7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Башлык М.З. Шәйдуллин